Республика Татарстан

Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул.Центральная, д. 30, пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү бистәсе,
Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15 » ноябрь 2019 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 11.11.2019 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 27 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.;
- үткәрү урыны – Үзэк ур, йор. № 12

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Җиңү авылы, Үзэк урамы, 30 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Загорье торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
-Загорье торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Загорье бистәсендә урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Загорье бистәсендә юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Вахитов авылы, Үзәк ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: И.Б.Бухарова